РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 35 2020 елның 21 декабре

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2019 елның 6 июнендәге 33 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставының 61 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2019 елның 6 июнендәге 33 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турында нигезләмәне раслау хакында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карар исемендә «иминиятләштерү» сүзен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

карар преамбуласында «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен өстәргә;

карарның 1 пунктында «иминиятләштерү» сүзен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны» сүзләреннән соң өстәргә;

карарга кушымтада:

исемендә «иминиятләштерү» сүзен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны» сүзләреннән соң өстәргә;

1 нче пунктта:

«муниципаль хезмәткәрләр» сүзләрен «даими нигездә эшләүче муниципаль вазыйфага билгеләнгән затлар һәм муниципаль хезмәт вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга,

«җирлекләр составына» сүзләрен «(алга таба - муниципаль вазифа биләүче затлар, хезмәткәрләр)» сүзләреннән соң өстәргә,

«зыяны» сүзен «аларның» сүзеннән соң өстәргә,

«муниципаль хезмәткәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль вазыйфаны биләүче затларның, хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт узуның бөтен чоры дәвамында гомере һәм сәламәтлеге мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүгә тиеш, ул муниципаль вазыйфа биләп торучы затның вазыйфага билгеләнү көненнән вәкаләтләре туктатылган көнгә кадәр яисә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгән (алга таба – вазыйфадан азат итү) көнгә кадәр исәпләнә.»;

3 нче пунктта:

«кайда» сүзеннән соң түбәндәге сүзләр өстәргә: «муниципаль вазыйфаны биләп торалар яки»,

«муниципаль хезмәткәрләр» сүзләрен «муниципаль вазыйфаны биләүче затлар, хезмәткәрләр» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның тугызынчы абзацында «граждан хезмәткәрләре» сүзләрен «муниципаль вазыйфа биләүче затлар, хезмәткәрләр» сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы пунктта:

беренче җөмләдә «Муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү» сүзләрен «Муниципаль вазыйфаны биләүче затларны, хезмәткәрләрне вазыйфаларыннан азат итү» сүзләренә алмаштырырга, «күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү датасыннан» сүзләрен «күрсәтелгән затларны вазыйфадан азат итү датасыннан» сүзләренә алмаштырырга,

икенче җөмләдә «муниципаль хезмәткәргә» сүзләреннән соң «карата» сүзен «муниципаль вазыйфа биләүче затларга, хезмәткәрләргә» сүзләренә алмаштырырга, текст буенча «әлеге муниципаль хезмәткәр» сүзләрен «әлеге затлар» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта:

1,2 пунктчаларда текст буенча «муниципаль хезмәт үткән чорда» сүзләрен «муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән чорда» сүзләренә алмаштырырга, «вазыйфасыннан азат итү» сүзләре алдыннан «муниципаль хезмәт» сүзләрен төшереп калдырырга,

3 пунктчада «муниципаль хезмәт үткән чорда» сүзләрен «муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән чорда» сүзләренә алмаштырырга,

4 пунктчада «муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан һәм муниципаль хезмәттән азат ителүдән» сүзләрен «муниципаль вазыйфаны биләүче затларны, хезмәткәрләрне вазыйфадан» сүзләренә алмаштырырга;

8 нче пунктта:

«вазыйфаны» сүзен «вазыйфа белән» сүзенә алмаштырырга,

«(алга таба – оклад)» сүзләреннән соң «, ә муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата - айлык акчалата бүләктән (алга таба – бүләкләү) чыгып»;

9 нчы пунктта:

1,2 пунктчаларда текст буенча «муниципаль хезмәт үткән чорда» сүзләрен «муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән чорда» сүзләренә алмаштырырга, «вазыйфасыннан азат итү» сүзләренә кадәр «муниципаль хезмәт» сүзләрен төшереп калдырырга,

3 пунктчада «муниципаль хезмәт үткән чорда» сүзләрен «муниципаль вазыйфа яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән чорда» сүзләренә алмаштырырга,

4 пунктчаның беренче абзацында «муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан һәм муниципаль хезмәттән азат итү» сүзләрен «муниципаль вазыйфаны биләүче затларны, хезмәткәрләрне вазыйфадан» сүзләренә алмаштырырга,

4 пунктчаның икенче абзацында «муниципаль хезмәт узган чорда» сүзләрен «муниципаль вазыйфаны яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән чорда» сүзләренә алмаштырырга, «вазыйфасыннан азат итү» сүзләренә кадәр «муниципаль хезмәт» сүзләрен төшереп калдырырга;

9,12 пунктларда текст буенча тиешле санда һәи килештә «оклад» сүзен тиешле санда һәм килештә «оклад (бүләкләү)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин